# Көз

***Кырлар буш кала***
***Яңгырлар ява;***
***Җирләр дымлана,-***
***Бу кайчак була?***

WWW.SUPERWALLPAPERS.RU

# Көз билгеләре

- **Көн кояшлы.**
- **Көн болытлы.**
- **Салкын җил исә.**
- **Агачларда сары, кызыл яфраклар.**
- **Кар ява.**
- **Яңгырлар ява.**
- **Көн җылы.**
- **Кошлар сайрый.**

Кәрзинемдә кыярлар,
Помидор һәм алмалар.



**Көз, Көз, әйт әле!
Кәрзинеңдә
ниләр бар?**

**Кәрзинемдә кыярлар,
Помидор һәм алмалар.**

**Көз, Көз, әйт әле!
Кәрзинеңдә
ниләр бар?**

**Кәрзинемдә сары, кызыл,
Алтын, матур төсләр
бар!**

Шаяра әле күбәләк,
Үтсәләр дә җәйләре.
Ә урамга килеп керде
Килде яфрак бәйрәме.
Нинди генә төсләре юк,
Күреп исең китәрлек
Яфрак ява яфрак ява
Юлыбызга түшәлеп

# “ Алтын сукмак буйлап көз атлый”

Көз

КӨЗ

**_Кояш офык ишегеннән_**
**_Керергә кыймый тора_**
**_Йөзен борды,колак салды_**
**_Торналар тавышына_**.
**_“Торык-торыйк,торыйк-торыйк”,-_**
**_Китеп бара торналар._**
**_Соңгы кат авыл өстендә_**
**_Нур белән коеналар._**
**_Кояш аларны җылытып_**
**_Озатты ерак юлга._**
**_Артларыннан, яулык болгап._**
**_Болыт килә авылга_**.
**_“Исән-сау барып җитегез”,-_**
**_Диде дә торналарга,_**
**_Йомшак күңелле шул болыт,_**
**_Әй, тотынды еларга..._**

## Сүзлек эше

ОФЫК- небосклон,горизонт


КЫЙМЫЙ- яхшысынмый

НУР БЕЛӘН КОЕНАЛАР- нурга күмеләләр

1.Шигырьдә кояш һәм болыт нинди эшләр башкаралар? Шул сүзләрне табып укып күрсәт.

2.Болыт ни өчен елый? Торналар киткәнгәме? Аңа күңелсезме?

Җансыз предметны, күренешне җанлы итеп күрсәтү- СЫНЛАНДЫРУ дип атала.



Физкультминутка







# Көзге уңыш



# Җиләк-җимешләр бакчасы











foto S.Makarenkova www.gribnickspb.narod.ru




# Яшелчәләр бакчасы

























***Көзге табын***

***Көзге табын-бай табын,***
***Кыяр,карбыз һәм кавын***
***Телем-телем теленгән.***
***Өем-өем өелгән.***

***Алмалары ал төсле,***
***Балкып туган таң төсле.***
***Капсаң эри авызда,***
***Һәр кисәге бал төсле.***

***Ә җимеше, җимеше,***
***Ачысы бар,төчесе!***
***Яңа пешкән күмәчтер***
***Кайнар кояш төслесе.***

***Әткәм кебек тырыш көз,***
***Әнкәм кебек юмарт көз.***
***Көзләр юмарт булганга,***
***Бик бәхетле, бик шат без.***

***Фәнис Яруллин***



# Сүзлек эше

Табын- стол,накрытый стол с едой

Телемләргә- разрезать на ломтики

Телем-телем- ломтиками



**1.Шигырь ни өчен “Көзге табын” дип атала?**

**“Көзге табын-бай табын”диелә шигырдә.Табынның байлыгын сурәтләгән юлларны табып укы.**

**2.Ни өчен көз әти-әни белән чагыштырылган икән?**

**3.Шигырдә нинди чагыштырулар бар,аларны табып укы.**

**ЧАГЫШТЫРУ-**

**нинди дә булса предметны яки күренешне аңа охшаш ягы булган**
**икенче предмет яки күренеш белән**

**чагыштырып сурәтләү.Чагыштыруда кебек,**

**шикелле,төсле сүзләре һәм –дай, -дәй,-тай,-тәй,төсле сүзләре**

**кулланыла.**

# Өй эше:

«Көз » 55нче  бит шигырьне ятларга;

Сынландыру 57нче бит, чагыштыру 62нче нче бит 5.(яз.)


famster.ru
Яшелчә
Җиләк-җимеш